Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Республики Татарстан
423644, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы

423644, Менделеевск районы, Монашево авылы,
Мэктэб урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-73-18
E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.01.2025 года № 1

«Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Монашево авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында»Татарстан
Республикасы Менделеевск муниципаль
районы Монашево авыл җирлеге Советы
карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясына, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге халкының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, гавами тыңлаулар уздыру юлы белән,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы карары проекты проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Мальгин Г.А.- Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл

җирлеге Советы рәисе урынбасары;

Семяков С.А. - социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм депутат этикасы буенча даими комитет рәисе;

Григорьева Н.С. - Монашево авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы карары проектына халыктан тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм кабул итүнең түбәндәге тәртибен билгеләргә.

Искәрмәләр, төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр язма рәвештә фамилиясе, исеме, атасының исемен, туган елын, авторның өй адресын күрсәтеп кабул ителә.

Килгән кисәтүләрне, төзәтмәләрне һәм тәкъдимнәрне эш көннәрендә Менделеевск районы, Монашево авылы, Мәктәп урамы, 19 йорт адресы буенча эш төркеме эш көннәрендә 8.00 сәг.16.00 сәг кадәр кабул итә һәм исәпкә ала.

4. Гамәлдәге законнар нигезендә гавами тыңлауларны 2025 елның 24 гыйнвары 16.00 сәгатьтә Менделеевск районы, Монашево авылы, Ленин ур. 18 йорт адресы буенча Монашево авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында җирлек Советы карары проекты буенча Монашево авыл җирлеге Советының 2018 елның 5 сентябрендәге 75 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикас хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru "Монашево авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов